Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел № 12

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Колшәрип авыл җирлеге
Колшәрип авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә, 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында Актау,Алиш,Әмир, Әмирхан, Болгар, Вахитов, Гыйлфанов, Җәлил, Дуслык, Заречная урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 23 ноябрендә, 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында Зеленая Роща, Ибраһимов, Урман, Маликов, Яшьләр, Усак тыкрыгы, Беренче май, Кыр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2019 елның 24 ноябрендә, 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында Елга, Сәйдәш, Совет, Сөләйман, Х.Такташ, Мәктәп, Х.Туфан, Ш.Усманов, Чапай урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2019 елның 24 ноябрендә, 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында Тукай, Көньяк, Яруллин, Яшьлек урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Колшәрип авылында юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Халык җыены этапларын Колшәрип авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Колшәрип авылы, Тукай урамы,50Б йорты.

7. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

8. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

10. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Колшәрип
авыл җирлеге башлыгы

Т.М. Бурмистрова